**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2022 елның «20» сентябреннән № 265

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «Шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарга сөтчелек юнәлешендә мини-фермалар төзү өчен агач (урман) материаллары, цемент һәм керамзит блоклар (төзелеш материаллары) сатып алуга субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 елның 9 февралендәге 54 номерлы карарына (2022 елның 26 маендагы 158 номерлы карардагы үзгәрешләр белән) үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2022 елның 5 апрелендәге 590 номерлы «Юридик затларга, шәхси эшмәкәрләргә, шулай ук товарлар җитештерүче, эшләр башкаручы, хезмәтләр күрсәтүче физик затларга субсидияләр, шул исәптән субсидияләр рәвешендә грантлар бирүне җайга сала торган норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга карата гомуми таләпләргә үзгәрешләр кертү турында, 2022 елда күрсәтелгән субсидияләрне һәм Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына федераль бюджеттан субсидияләр бирү үзенчәлекләре турында»гы карары нигезендә Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «Шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарга сөтчелек юнәлешендә мини-фермалар төзү өчен агач (урман) материаллары, цемент һәм керамзит блоклар (төзелеш материаллары) сатып алуга субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 елның 9 февралендәге 54 номерлы карарына (2022 елның 26 маендагы 158 номерлы карардагы үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

күрсәтелгән карар белән расланган Шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы

гражданнарга сөтчелек юнәлешендә мини-фермалар төзүгә агач (урман) материаллар, цемент һәм керамзит блоклар (төзелеш материаллары) сатып алуга субсидияләр бирү тәртибендә:

19 пунктны түбәндәге редакциядә бирергә:

«19. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты субсидия алучылар тарафыннан субсидия бирү тәртибен һәм шартларын, шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешен үтәүне тикшереп торалар. Муниципаль финанс тикшерү органнары Россия Федерациясе Бюджет кодексының 2681 һәм 2692 статьялары нигезендә тикшерүне гамәлгә ашыралар.».

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http://novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче Р.Р. Фасахов